ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА УРУССУ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423950, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы,
Пушкин урамы, 38

Тел.: 8(85593)2-92-40, факс: 2-61-50, e-mail: Pgt.Urussu@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27. 05 **2021 ел** **№ 14**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегендә алкоголь продукциясен ваклап сатуны чикләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон, "Җирле үзидарә органнары тарафыннан алкогольле продукцияне ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган территорияләр чикләрен билгеләү Кагыйдәләрен раслау турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 23.12.2020 ел, №2220 карары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында алкоголь продукциясен, сыра, тәмәке куллануны киметү һәм халык арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча өстәмә чаралар турында» 2010 ел, 29 октябрь, 867 нче карары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Советының 28.04.2020 ел, № 5 карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Советының 24.04.2017 ел, № 6 карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Башкарма комитеты турында Нигезләмәсе нигезендә, карар бирә:

1. Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитетының «Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән кайбер оешмаларга һәм территорияләргә якын урнашкан территорияләрнең чикләрен билгеләү турында» 2013 елның 15 мартындагы 12 номерлы карарын һәм Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Башкарма комитетының 15.06.2015 ел, №31 «Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы

Урыссу поселогы Башкарма комитетының «Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмалар һәм объектлар тирәсендәге территорияләр чикләрен билгеләү турында» 15.03.2013 ел, № 12 карарына үзгәрешләр кертү хакында"гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогында соңиаль-мәдәни объектларга, гражданнар күпләп җыела торган урыннарга һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган югары куркыныч чыганаклары урнашкан урыннарга якын территорияләр исемлеген расларга. (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән объектка керүчеләр өчен керү урыныннан тротуарлар, җәяүлеләр юллары һәм җәяүлеләр өчен чыгу юлларыннан йә аларның аерымланган территориясенә керү (ул булган очракта) алкоголь продукциясен ваклап сату яисә җәмәгать туклануы предприятиесенә керү юлына кадәр араны билгеләргә. Ераклыкларны үлчәү җәяүлеләр хәрәкәтенең иң кыска маршруты буенча башкарыла.

4. Гражданнар күпләп җыела торган урыннарда шәһәр чараларын уздырган вакытта сәүдә предприятиеләре җитәкчеләренә чаралар үткәрелә торган урыннарда да, алар янындагы территорияләрдә дә кимендә 300 метр радиуста урнашкан сәүдә объектларында алкоголь продукциясен ваклап сатуны туктатырга тәкъдим итәргә.

5. Россия Эчке эшләр министрлыгының Ютазы районы буенча бүлегенә сәүдә предприятиеләре эшенең әлеге карар таләпләренә туры килүенә тикшерүләр оештыруны тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында http://jutaza.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче вазыйфаларын вакытлыча башкаручы З.З. Гыйбадуллина

1 нче кушымта
Урыссу шәһәр тибындагы поселогы
Башкарма комитеты карары
белән расланды
"27" 05 2021 ел № 14

Урыссу шәһәр тибындагы поселогындагы алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән социаль-мәдәни объектларга һәм югары куркыныч чыганаклары урнашкан урыннарга якын территорияләр
ИСЕМЛЕГЕ

| №№ т/б | Объект исеме | Якындагы территориянең чикләре |
|---|---|---|
| 1 | Автовокзаллар | Керү ишекләреннән 10 метрдан ким булмаган зонада. |
| 2 | Балалар, белем бирү оешмалары (шул исәптән студентлар һәм укучылар өчен тулай тораклар) урнашкан биналар һәм корылмалар | Керү ишекләреннән 10 метрдан ким булмаган зонада. Әгәр бу балалар, мәгариф оешмалары шулай ук ихаталап алынган җир кишәрлеген үз эченә алса, килүчеләр өчен иң якын керү урыныннан . |
| 3 | Медицина оешмалары урнашкан биналар һәм корылмалар | Керү ишекләреннән 10 метрдан ким булмаган зонада. Әгәр бу медицина оешмалары шулай ук ихаталап алынган җир кишәрлеген үз эченә алса, килүчеләр өчен иң якындагы керү урыныннан . |
| 4 | Спорт объектлары | Керү ишекләреннән 10 метрдан ким булмаган зонада. Әгәр бу спорт объектлары шулай ук киртәләп алынган җир кишәрлеген үз эченә алса, килүчеләр өчен якындагы керү урыныннан. |
| 5 | Күпләп һәм ваклап сату базарлары | Керү ишекләреннән 10 метрдан ким булмаган зонада. |